ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 20.09.2024

**К А Р А Р** № 877

**Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, Күлле п. адресы буенча Территорияне планлаштыру проектын раслау турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге 361 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы территориясен планлаштыру проектларын, территорияләрне ызанлау проектларын әзерләү, территорияне планлаштыру проектларын, территорияләрне ызанлау проектларын тикшерү һәм раслау турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, Күлле п. адресы буенча территорияне планлаштыру проектын раслау буенча 2024 елның 29 августындагы Семиозерка авыл җирлеге Советы үткәргән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, Күлле п. адресы буенча территорияне планлаштыру проектын расларга.

2. Әлеге карарны, кызыл сызыкларның характерлы нокталары координаталары исемлегеннән тыш (кызыл сызыклар күрсәтелгән план проекты сызымына кушымта) (хезмәттә куллану өчен материаллар) Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына гамәлдәге законнар нигезендә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә

Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына тиешле белешмәләр кертү өчен әлеге карарның күчермәсен җибәрергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Р.Ш. Хисаметдиновка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф.Хәкимуллин